КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 ноябрь г.Казань № 1244

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карары белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 апрель, 283 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1202 нче; 2021 ел, 19 март, 148 нче һәм 2022 ел, 18 июль, 686 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$3^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3[1]. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

12 пунктның беренче абзацында «субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткече» сүзләрен «субсидия бирү тәгәлләнә торган төгәл дата һәм аны бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның төгәл микъдари тасвирнамәсе)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин